КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 апрель г.Казань № 308

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 16 декабрь, 1239 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидияләр бирү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының ветеринария лабораторияләре тарафыннан аккредитацияләүнең милли системасында аккредитация алу һәм (яисә) аларның аккредитацияләү өлкәсен киңәйтү өчен шартлар тудыруны финанс белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы, «Бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгеле торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнгән һәм «Халыкара кооперация һәм экспорт» илкүләм проекты составына керүче «Агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында аккредитацияләүнең милли системасында ветеринария лабораториясен аккредитацияләү өлкәсен киңәйтүне дә кертеп, 2019 елдан башлап ветеринария лабораториясе тарафыннан тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба - ветеринария лабораториясе) субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели (алга таба - Тәртип, субсидия):

ветеринария лабораториясе бинасын (бүлмәләрен) реконструкцияләүгә, капиталь яисә агымдагы ремонтлауга чыгымнар, вивария;

җиһазларны модернизацияләүгә һәм (яисә) сатып алуга чыгымнар;

ветеринария лабораториясе хезмәткәрләрен укытуга чыгымнар;

лабораторияара сынаулар уздыруга чыгымнар.

1.2. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчаларын алучы буларак бюджет акчаларын баш бүлүчегә - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә (алга таба - Ветеринария идарәсе) җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.3. Әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында каралган субсидияне финанс белән тәэмин итү чыганагы - федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Агымдагы финанс елында субсидия алу өчен ветеринария лабораториясе Ветеринария идарәсенә агымдагы елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча түбәндәге документларны җибәрә:

а) ирекле рәвештә төзелгән субсидия бирүгә гариза;

б) әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү кирәклеген нигезләп аңлатма язуы, субсидия суммасын исәпләүне дә кертеп;

в) тотылган чыгымнарны раслый торган документлар:

ветеринария лабораториясе бинасын (бүлмәләрен) реконструкцияләүгә, капиталь яисә агымдагы ремонтлауга, вивария;

лаборатория бинасын техник тикшерү актының күчермәсен, реконструкцияләнергә тиешле вивария, капиталь яисә агымдагы ремонт актының күчермәсен;

махсуслаштырылган оешма тарафыннан төзелгән дефектлы ведомость күчермәсен;

махсуслаштырылган оешма тарафыннан төзелгән һәм ветеринария лабораториясе җитәкчесе тарафыннан расланган смета (җыелма смета исәбе) күчермәсен;

лаборатория, вивария бинасын реконструкцияләү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау эшләрен уздыруга шартнамәләрнең күчермәләрен;

ветеринария лабораториясенең шәхси счетыннан түләү йөкләмәләре һәм өземтәләре күчермәләре;

башкарылган эшләр кабул итү актлары күчермәләрен (КС-2);

башкарылган эшләр бәясе һәм чыгымнар турында белешмәләр күчермәләрен (КС-3);

җиһазларны модернизацияләүгә һәм (яисә) сатып алуга:

җиһазларны модернизацияләүгә һәм (яисә) сатып алуга шартнамәләрнең күчермәләрен;

ясалма һәм (яисә) универсаль тапшыру документларының, счет-фактураларның (булган очракта), күрсәтелгән хезмәтләрне, башкарылган эшләрне кабул итү актларының күчермәләре;

ветеринария лабораториясе хезмәткәрләрен укытуга:

ветеринария лабораториясе хезмәткәрләрен укытуга шартнамәләрнең күчермәләрен;

ясалма һәм (яисә) универсаль тапшыру документларының, счет-фактураларның (булган очракта), күрсәтелгән хезмәтләрне, башкарылган эшләрне кабул итү актларының күчермәләре;

лабораторияара чагыштырма сынаулар уздыруга:

лабораторияара чагыштырма сынаулар уздыруга шартнамәләрнең күчермәләрен;

ясалма һәм (яисә) универсаль тапшыру документларының, счет-фактураларның (булган очракта), күрсәтелгән хезмәтләрне, башкарылган эшләрне кабул итү актларының күчермәләре;

г) ветеринария лабораториясен аккредитацияләү өлкәсен киңәйтү турында аккредитацияләү буенча милли орган документының күчермәсен;

д) салым органының салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турындагы белешмә кәгазен;

е) Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау турында белешмә;

ж) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасын төзү, үстерү һәм эксплуатацияләү тәртибе турында» 2016 елның 7 ноябрендәге 1140 номерлы карары нигезендә «Веста» ветеринария өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасы компонентына мәгълүмат бирү турында белешмәләр.

2.2. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар ветеринария лабораториясе җитәкчесенең яисә аның вазыйфаларын башкаручы затның имзасы белән таныклана һәм кәгазь чыганакта Ветеринария идарәсенә җибәрелә.

Әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә бирелә торган документлардагы белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык ветеринария лабораториясенә йөкләнә.

2.3. Субсидия алу өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның 1 көненә ветеринария лабораториясе туры килергә тиешле таләпләр:

ветеринария лабораториясенең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

ветеринария лабораториясенең федераль бюджетка һәм Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы булмаска тиеш.

2.4. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән алып 10 эш көне эчендә Ветеринария идарәсе аларны карый һәм субсидия бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Кабул ителгән карар турында Ветеринария идарәсе ветеринария лабораториясенә тиешле карар кабул ителгән көнне язма рәвештә хәбәр итә.

2.5. Ветеринария лабораториясенә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

«ветеринария лабораториясе тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки аларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);»;

ветеринария лабораториясе тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

ветеринария лабораториясенең әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

Ветеринария идарәсенә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын бетерү.

2.6. Әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча субсидия бирүдән баш тарткан очракта, ветеринария лабораториясе әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны кабат Ветеринария идарәсенә тапшырырга хокуклы, субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булган искәрмәләрне бетерү шарты белән.

2.7. Кабат тапшырылган документларны карау әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.8. Ветеринария лабораториясе әлеге Тәртипнең 2.4 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидия бирү турында хәбәрнамә юллаган көннән алып биш эш көне эчендә Ветеринария идарәсе һәм ветеринария лабораториясе арасында субсидия бирү турында килешү төзелә (алга таба - Килешү).

Килешү, шул исәптән күрсәтелгән Килешүгә үзгәрешләр кертүне яисә аны өзүне күздә тоткан өстәмә килешү, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк формалар нигезендә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасын кулланып төзелә.

2.9. Килешүдә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрнең 4 пунктындагы «д» пунктчасында каралган нигезләмәләрдә бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган нигезләмәләр булырга тиеш.

2.10. Ветеринария лабораториясенә әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында (С) каралган максатларга субсидияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = \sum Z_{р} + Z_{м} + Z_{о} + Z_{i},$$

монда:

$Z_{р}$ – ветеринария лабораториясе бинасын (бүлмәләрен) реконструкцияләүгә, капиталь яисә агымдагы ремонтлауга чыгымнар, вивария;

$Z_{м}$ – җиһазларны модернизацияләүгә һәм (яисә) сатып алуга чыгымнар;

$Z_{о}$ – ветеринария лабораториясе хезмәткәрләрен укытуга чыгымнар;

$Z_{i}$ – лабораторияара чагыштырма сынаулар уздыруга чыгымнар.

Әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында каралган максатларга ветеринария лабораториясе тарафыннан башкарылган чыгымнар әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән документлар белән расланырга тиеш.

Субсидия зурлыгы әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларг Ветеринария идарәсенә билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаска тиеш.

2.11. Субсидия күчерү Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгында ачылган ветеринария лабораториясенең шәхси счетына Килешү төзелгән көннән соң килүче
10 нчы эш көненнән соңга кламыйча бер тапкыр гамәлгә ашырыла.

2.12. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып субсидияләр бирү елның 31 декабренә кадәр ветеринария лабораториясен аккредитацияләү өлкәсен киңәйтү турында аккредитацияләнгән затлар реестрына кимендә бер язма кертү тора.

## III. Хисаплылыкка карата таләпләр

3.1. Ветеринария лабораториясе Ветеринария идарәсенә субсидия бирү нәтиҗәсенең мөһимлеге турындагы хисапны, субсидия бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслаган субсидия бирү турындагы килешүнең үрнәк формасында билгеләнгән рәвештә тапшыра.

3.2. Ветеринария идарәсе Килешүдә ветеринария лабораториясе тарафыннан хисаплылык бирүнең өстәмә рәвешләрен һәм аларны бирү срокларын билгеләргә хокуклы.

## IV. Субсидия бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүдә тоту тәртибе һәм грант бирү тәртибе һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

4.1. Ветеринаия идарәсе һәм дәүләт финанс контроле органнары ветеринария лабораториясе тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.2. Субсидия ветеринария лабораториясе тарафыннан Ветеринария идарәсенең тиешле таләпләрен алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш, ветеринария лабораториясе тарафыннан Ветеринария идарәсе һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозу очракларында тулы күләмдә.

4.3. Әлеге Тәртипнең 2.12 пунктында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү факты Ветеринария идарәсе яисә дәүләт финанс контроле вәкаләтле органнары тарафыннан билгеләнгән очракта, субсидия Татарстан Республикасы бюджетына аларны билгеләгән көннән алып 30 календарь көн эчендә тулы күләмдә кайтарылырга тиеш.

4.4. Ветеринария лабораториясе тарафыннан әлеге Тәртипнең 4.2 һәм 4.3 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Ветеринария идарәсе субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына

Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

4.5. Бирелә торган субсидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Ветеринария идарәсе тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.